АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, Проспект Ленина,дом 58.Тел.3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-44-40

# КАРАР

№ 2 «18» гыйнвар 2021 ел

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитетының 2021 елга эш планы турында

Актаныш авыл башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшчәнлеген тормышка ашыру максатыннан, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шариповнын 2021 елга Актаныш авыл башкарма комитетының эш планы турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитетының 2021 елга эш планын кушымта нигезендә расларга.

2 Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш авыл
Башкарма комитеты житәкчесе Р.Р.Шарипов

Актаныш авыл башкарма
комитетынын 2021 елнын «18» гыйнварыннан
№ 2 санлы карарына кушымта

## Актаныш авыл башкарма комитетының 2021 елга эш планы

| № п\п | Эш торе | вакыты | жаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Актаныш муниципаль районы Советы, башкарма комитетының атналык эшен планлаштыру буенча киңәшмәләрдә катнашу | даими | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2 | Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитетының 2021 елга эш планын кабул итү | Январь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 3 | Авыл башкарма комитеты каршында төзелгән комиссияләр һәм советларның эш планнарын раслау | январь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 4 | Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча норматив-хокукый актларны әзерләү һәм кабул итү | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, җитәкче урынбасары |
| 5 | Законнар нигезендә муниципаль программалар әзерләү | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, җитәкче урынбасары |
| 6 | Муниципаль сатып алулар үткәрү өчен конкурс, аукцион документларын эшләү | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитетның икътисад бүлегенең сатып алулар буенча белгечләре |
| 7 | Шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, җитәкче урынбасары |
| 8 | Авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү | Январь-апрель | Авыл башкарма комитеты |
| 9 | Муниципаль хезмәткәрләрнең район спартакиадасында катнашу | январь | Авыл башкарма комитеты |
| 10 | Учреждение, оешма, предприятие, авыл җирлекләре хезмәткәрләре арасында чаңгы эстафетасында катнашу | январь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 11 | Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елгы эшчәнлеге турында хисабы | Январь-февраль | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 12 | Чираттагы финанс елына бюджет үтәлеше турында хисап һәм хисап әзерләү | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, ҮБ МБУ әйдәп баручы хисапчысы |
| 13 | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуны оештыру | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, ИТК ҖЧҖ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | Җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү | Апрель-октябрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, ИТК ҖЧҖ |
| 15 | Кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тотуга контроль | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, «Актаныш юллары» ҖЧҖ, ИТК ҖЧҖ |
| 16 | Зарарланган юл билгеләрен алыштыру, яна юл билгеләре урнаштыру | Апрель-октябрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, Актаныш районы буенча ЮХИДИ булекчәсе, «Татавтодор» ААҖ, «Актаныш каты көнкүреш калдыклары полигоны» МУП |
| 17 | Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган чарада катнашу | март | Авыл башкарма комитеты |
| 18 | Җирлек территориясен санитар чистарту, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча икеайлыкны оештыру | Апрель-май | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 19 | Җирлек территориясен яшелләндерү эшләрен оештыру | Апрель-октябрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, Җирлек территориясен төзекләндерү буенча комиссия |
| 20 | Тупылларны сирэклэу, агачларны кису | Апрель-октябрь | Җирлек территориясен төзекләндерү буенча комиссия |
| 21 | Җирләү урыннарын карап тоту, зиратларны агачлардан, куак үсемлекләреннән,чүп-чардан чистарту | Апрель-октябрь | Ветераннар советы, Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләре |
| 22 | Түбән Актанышта шәхси ярдәмче хуҗалыкларның мал көтүен оештыру | Май-октябрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, әйдәп баручы белгечләр |
| 23 | Халыкны оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр территорияләрен чүп-чардан, коры үләннән чистарту буенча иҗтимагый әһәмиятле эшләргә җәлеп итү; массакүләм өмәләр оештыру | Апрель-октябрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләре |
| 24 | Массакүләм чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары белән хезмәттәшлек | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе,эчке эшләр бүлеге, ЮХИДИ бүлекчәсе |
| 25 | Җирлектә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү эшен оештыру, имин булмаган | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гаиләләр,күп балалы гаиләләр, ялгыз өлкәннәр йортларында АПИ урнаштыру, янгынга каршы инструктаж үткәрү | | «Яран»ТМШ, социаль яклау бүлеге |
| 26 | Аз керемлеләр, ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр, инвалидлар, ветераннар белән эшне оештыру | даими | комиссия |
| 27 | Социаль куркыныч хәлдә булган, имин булмаган гаиләләргә кучмә рейдлар үткәрү | даими | комиссия |
| 28 | Авыл җирлекләре белән үткәрелә торган киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу, җирлекләрнең эш тәҗрибәсен өйрәнү һәм уртаклашу | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе |
| 29 | Адреслы хуҗалыкны тәртипкә салу, электрон хуҗалык кенәгәсенең мәгълүматлар базасын яңарту һәм тулыландыру буенча эшне оештыру | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты әйдәп баручы белгечләре |
| 30 | Оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләре һәм халык белән үзара салым акчаларын җыю буенча эш | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты |
| 31 | Җиңү бәйрәменә багышланган чаралар планын эшләү ( Бөек Ватан сугышы ветераннарын, тыл хезмәтчәннәрен, сугышта катнашучыларның тол хатыннарын хөрмәтләү) | 07.05-09.05 | Авыл башкарма комитеты |
| 32 | «Сабантуй-2021» милли бәйрәмен әзерләү һәм уздыру | июнь | комиссия |
| 33 | Спорт чараларында катнашу | Май-сентябрь | Авыл башкарма комитеты |
| 34 | «Мәктәпкә җыенырга булыш» акциясендә катнашу | август | Авыл башкарма комитеты |
| 35 | Муниципаль сайлауларны үткәрү буенча оештыру эшләре һәм матди-техник тәэмин итү | сентябрь | Авыл башкарма комитеты,участок сайлау комиссияләре, территориаль сайлау комиссиясе |
| 36 | Җирлекнең урам утларына техник хезмәт күрсәтү һәм урам утларын модернизацияләү эшләрен оештыру | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, “Актаныш каты көнкүреш калдыклары полигоны” МУП |
| 37 | Урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую эшен оештыру | ел дәвамында | Авыл башкарма комитеты, “Яран “ТМШ |
| 38 | Өлкәннәр көненә багышланган чараларда катнашу, өлкәннәрнең өйләренә бару | 1-10 октябрь | Авыл башкарма комитеты |
| 39 | Җир, мөлкәт һәм транспорт салымын җыю буенча халык белән эшне оештыру | Октябрь-ноябрь | Авыл башкарма комитеты, ФБП |
| 40 | Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча халык җыеннарын оештыру һәм үткәрү | ноябрь | Авыл башкарма комитеты, участок сайлау комиссияләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 41 | Инвалидлар декадасы. Инвалидлар көненә багышланган чаралар. “Игелек марафоны" хәйрия акциясендә катнашу | 1-10 декабрь | Авыл башкарма комитеты, җирлек Советы депутатлары |
| 42 | 2022 елга җирлек бюджеты проектын формалаштыру һәм әзерләү | Ноябрь, декабрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, ҮБ МБУ әйдәүче хисапчысы |
| 43 | Җирлек территориясендә урнашкан оешмалар,учреждениеләр, предприятиеләр, сәүдә объектларының фасадларының Яңа елга бизәлешен оештыру | 20-31 декабрь | Авыл башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия |

Искәрмә: турыдан-туры авыл башкарма комитетына буйсынмаган җаваплы башкаручылар килешенү буенча кертелә.